| | | |
|---|---|---|
| **СОВЕТ ИРКЕНЯШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИРКӘНӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**11 ноябрь 2019 ел.** **№1**

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге составына кергән Яңа Иркәнәш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

1. 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 11 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде: "2020 елда Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Яңа Иркәнәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?"

- Хуҗасыз җирләрне киртәләү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 23 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 12.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучыларның 12 ;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның _0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Яңа Иркәнәш торак пунктында гражданнар җыенын - узган, гражданнар жыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иркәнәш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, (1 һәм 2 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш - халык саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан да артмый торган), 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны жирле әһәмияткә ия мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерү белән бәйле сорау белән килешәсезме:

-Хуҗасыз җирләрне киртәләп алу.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иркәнәш авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында: http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар жыенында рәислек итүче: Камалов И.Р.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе: Касыймов И.З.